Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Кукмара шәһәре Советы

КАРАР

2019 елның 24 маеннан № 7

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 6 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре җирлеге Советы карар бирде:

I. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 22 пунктындагы 5 статьяда «шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә (алга таба – планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә) күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында хәбәрнамә,... планлаштырылган шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты төзү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве яисә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкин булмавы турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә

шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрү, Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү турында карар, үзбелдекле төзелешне җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына, капиталь төзелеш объектларын җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән реконструкцияләүгә яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры китерү (алга таба шулай ук – билгеләнгән таләпләргә туры китерү) турында карар, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү» сүзләрен өстәргә;

2) 1 бүлекнең 5 статьясында 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«29) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм волонтерлыкка (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтү;»;

3) 1 бүлекнең 39 пунктының 5 статьясында «күчемсез милекнең дәүләт кадастры» сүзләрен «кадастр эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяда 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 16 нчы пунктны өстәргә:

«16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

5) 19 статьяда 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гавами тыңлаулар халык, җирлек Советы, җирлек Башлыгы яки Башкарма комитет Җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә. Халык яки җирлек Советы инициативасы белән үткәрелә торган гавами тыңлаулар – җирлек Советы, ә җирлек Башлыгы яки җирлекнең Башкарма комитет җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торганы җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

6) 48 статьяда 1 бүлекнең 4 пунктындагы сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне, юл хәрәкәтен оештыруны да кертеп, шулай ук автомобиль юлларыннан һәм юл эшчәнлегеннән файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкара;

7) 48 статьяда 5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «-җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итә, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм волонтерлыкка (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтә;»;

8) 48 статьяда 1 бүлекнең 6 пунктындагы 12 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

9) 48статьяда 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

««Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра»;

10) 75 статьяда 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган шартнамәләр рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип, аның тулы текстын муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугатта бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәрле басмадан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның рәсми челтәр басмасында тулы тексты басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, күләмле график һәм таблица кушымталары басма матбугатта басылмаска да мөмкин.»;

11) 5 бүлекнең 75 статьясында «Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләреннән соң «,җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр,» сүзләрен өстәргә»;

12) 75 статьяда 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 8. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актларны, килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- хокукый акт текстын районның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган басма массакүләм мәгълүмат чараларында яки җирлек территориясендә таратыла торган бүтән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка массакүләм мәгълүмат чараларында бастырганда, әлеге басылуның рәсми булуы турында тамга булырга тиеш;

- хокукый акт текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы районның рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштыру;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру: www.pravo.tatarstan.ru;

- хокукый акт текстын җирлек торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашу урыннары җирлек Советы тарафыннан раслана һәм җирлек халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.»;

13) 92 статьяда 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзацны өстәргә:

«Муниципаль берәмлек Уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Юстиция министрлыгы порталында дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, регистрация в качестве сетевого издания: Эл № ФС77-72471 от 05.03.2018).»

II. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев